**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

01.07. 2026 ел № 2167

**«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына (Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2025 ел, № 756 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яки коммерциясез яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яки яшелчәчелек өчен булса) яисә бакчачылык яки коммерциясез яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган,

федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яки чираттан тыш сатып алу яисә әлеге Кодексның 39_18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык өчен булса) сатып алу хокукына ия гражданның мондый гариза белән мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш, шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса)»;

1.2. 2.8 бүлегенең 16 пунктында «чик» сүзен төшереп калдырырга;

1.3. 2.8 бүлегенең 13 пунктында «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 2.8 бүлегенең 9 пунктында «территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән,» сүзләрен өстәргә;

1.5. 2.8 бүлегенең 10 пунктында «территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән» сүзләреннән соң «яисә әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләрен өстәргә;

1.6. 2.8 бүлегенең 8 пунктында «территорияне үстерү» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү» сүзләренә алыштырырга;

1.7. Административ регламентка 1 кушымтада 39_6 статьяның 2 пункты 9 пунктчасында «бу күчемсез мөлкәт объектлары бирелде» сүзләрен «дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган биналар, корылмалар арендага бирелде,» сүзләренә алыштырырга;

1.8. Административ регламентка 1 кушымтада 4 бүлекнең 4.2.3 пунктында «барлыкка килә» сүзләреннән соң «яки туктатыла» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны ТР Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов